МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

16.05.2024 Казан ш. № 1347-р

Газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зонасын урнаштыру турында” 11.01.2024 № 7-р карарына үзгәреш кертү турында.

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматы фонды» ДБУның (07.05.2024 № 04А-04/965) хатын искә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зонасын урнаштыру турында” 11.01.2024 № 7-р карары (№ 7-р карары) белән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә урнаштырылган газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зонасын, газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зонасы чикләрен төзегәндә ачыкланган ялгышларны төзәтү белән бәйле рәвештә, «КБ-ПРОЕКТ» ҖЧҖ башкарган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп урнаштырырга үзгәртергә. Газ бүлү челтәрләренең саклык зонасының гомуми мәйданы территория рәвешендә (37122 ± 67) кв.м.ны тәшкил итә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «КБ-ПРОЕКТ» ҖЧҖ башкарган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, № 7-р Карарына үзгәреш кертеп, 1 пунктта «гомуми мәйданы (37266 ± 68) кв.м» дигән сүзләрне «гомуми мәйданы (37122 ± 67) кв.м» сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**